Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге составына керүче Рус Әшнәге авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

30 октябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге составына керүче Рус Әшнәге авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Рус Әшнәге авылындагы мәктәп, кыр урамнарын ремонтлау
- Рус Әшнәге авылларында контейнер мәйданчыклары ясау һәм төзекләндерү; ;
- Рус Әшнәге авылы урамнарының машиналар йөрү өлешен (урамнарны чистарту) кышкы карап тоту;
- Рус Әшнәге авылында суүткәргеч ремонтлау;

.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорты; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хаҗиев В.Х.

Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы Хаҗиев В.Х.